| ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПО ТАРИФАМ | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

10.11.2017 Казан ш. № 5-24/тэ

2018 елга «Аммоний» акционерлык җәмгыяте тарафыннан кулланучыларга җиткерелә торган җылыйөрткечкә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 09.12.2016 № 5-36/тэ карары белән билгеләнгән дәвамлы тарифларга үзгәрешләр кертү хакында

«Җылы белән тәэмин итү турында» 2010 елның 27 июлендәге 190-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Җылы белән тәэмин итү өлкәсендә бәя хасил итү турында» 2012 елның 22 октябрендәге 1075 номерлы карары, Федераль тарифлар хезмәтенең «Җылы белән тәэмин итү өлкәсендә җайга салынулы бәяләрне (тарифларны) хисаплау буенча методик күрсәтмәләр раслау турында» 2013 елның 13 июнендәге 760-э номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмә нигезендә һәм 2018-2019 елларга җайга салынулы оешмаларның планлы зарури тулай табышын тәгаенләштереп, 2018-2019 елларга җылыйөрткечкә дәвамлы тарифларга төзәтмәләр кертү максатларында, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының «2017-2019 елларга «Аммоний» акционерлык җәмгыяте тарафыннан кулланучыларга җиткерелә торган җылыйөрткечкә тарифлар билгеләү турында» 09.12.2016 № 5-36/тэ карарының 1 нче кушымтасына, аны яңа редакциядә бәян итеп, шушы карар кушымтасына туры китереп, үзгәрешләр кертергә.

2. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис М.Р.Зарипов

Татарстан Республикасы
Тарифлар буенча дәүләт комитетының
10.11.2017 № 5-24/тэ карарына кушымта
«Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының 09.12.2016
№ 5-36/тэ карарына 1 нче кушымта

# 2017-2019 елларга «Аммоний» акционерлык җәмгыяте тарафыннан җиткерелә торган җылыйөрткечкә календарь буенча бүленгән тарифлар

| № п/п | Муниципаль берәмлекнең, җайга салынучы оешманың аталышы | Тариф төре | Ел | Җылыйөрткеч төре | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | су | пар |
| | Кулланучыларга җиткерелә торган җылыйөрткечкә тариф | | | | |
| | Менделеевск муниципаль районы | | | | |
| 1 | «Аммоний» акционерлык җәмгыяте | бер ставкалы, сум/куб.м | 01.01.2017 башлап 30.06.2017 кадәр | - | 78,33 |
| | | | 01.07.2017 башлап 31.12.2017 кадәр | - | 82,65 |
| | | | 01.01.2018 башлап 30.06.2018 кадәр | - | 82,65 |
| | | | 01.07.2018 башлап 31.12.2018 кадәр | - | 84,67 |
| | | | 01.01.2019 башлап 30.06.2019 кадәр | - | 84,67 |
| | | | 01.07.2019 башлап 31.12.2019 кадәр | - | 88,50» |

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының тариф чишелешләрен кабул итүне оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге